# КАРАР

**29 ноябрь 2022 ел №1**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок-Шәмәрдән авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә 19.00 сәгатьтә һәм 2022 елның 29 ноябрендә 19.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Починок- Шәмәрдән авылында кышын-җәен юлларны карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Починок- Шәмәрдән авылының Совет урамнары буенча юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү,техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;
- янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылы чишмәсен һәм территорясен төзекләндерү, ремонтлау (материаллар алу), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- су белән тәэмин итү челтәрләре өчен проект-смета документларын эшләү, су белән тәэмин итү трассасын үткәрү һәм ремонтлау, су насосын алу һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылында зиратларны карап тоту, материалар, инструментлар сатып алу, койма урнаштыру һәм килешү буенча түләү;

- Починок-Шәмәрдән авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү һәм килешү буенча түләү

«ӘЙЕ» «ЮК».

Халык җыенының Йомгаклау протоколы нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 170 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 88 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

Җыенда катнашкан 88 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок - Шәмәрдән авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Починок- Шәмәрдән авылында кышын-җәен юлларны карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Починок- Шәмәрдән авылының Совет урамнары буенча юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү,техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү;

- Починок-Шәмәрдән авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;

- янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Починок-Шәмәрдән авылы чишмәсен һәм территорясен төзекләндерү, ремонтлау (материаллар алу), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- су белән тәэмин итү челтәрләре өчен проект-смета документларын эшләү, су белән тәэмин итү трассасын үткәрү һәм ремонтлау, су насосын алу һәм килешү буенча түләү;

- Починок-Шәмәрдән авылында зиратларны карап тоту, материалар, инструментлар сатып алу, койма урнаштыру һәм килешү буенча түләү;

- Починок-Шәмәрдән авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү һәм килешү буенча түләү"?

«ӘЙЕ» «ЮК»

- кабул ителгән.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ядегәр авылы җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ЯДЫГЕРЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ"
ОГРН 1021607752836
Совет Ядыгерьского сельского поселения
ИНН 1623001639